**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ТЕНЕШ**

**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЁЛОГЫ**

**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**

# КАРАР

Тенеш ш.т.б. № 39-рс

**Поселок Советы тарафыннан 2021 елның 16 декабрендә кабул ителде**
**Тенеш бистәсе башлыгы тарафыннан 2021 елның 16 декабрендә имзаланды**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 20 апрелендәге 29-рс номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 25.06.2013 № 50-ТРЗ, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 20 апрелендәге 29-рс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 бүлекнең 1 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«9) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы,

муниципаль хезмәткәргә шул турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданствосы) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданлыгы) турында язма рәвештә хәбәр итәргә».

**2) 11 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:**
«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында йә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы чит ил документы яисә башка документ алу турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, ләкин чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча яисә гражданның чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән дә соңга калмыйча;»;

**3) 12 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;»;

**4) 12 бүлекнең 1 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«7) чит ил гражданлыгы (подданствосы) булу яисә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

**5) 15 бүлекнең 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми;

**6) 19 бүлекнең 1 пунктындагы 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы,Совет рәисе - И. Т. Гыйниятов